СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 26 сентябре № 39/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды» ДБУ тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Генераль планы материалларын карап, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2024 елның 13 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2024 елның 16 сентябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 7 һәм 29 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтындагы (www.droganoye.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров